Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Иске Иглай авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«12» ноябрь 2022 ел №4

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге Иске Иглай авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

Яңа Иглай авыл җирлеге Иске Иглай торак пунктында яшәүче 1 гр инвалидлардан, балачактан инвалид булганнардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол калган хатыннарыннан кала, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләр ветераннары, ялгыз яшәүче 75 яшьтән өлкәнрәкләрдән кала 2023 елда балигъ булган һәр кешедән 2023 елда 3000 сум күләмендә үзара салым кертергә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

-Иске Иглай авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы тоту.

- Иске Иглай авылында урам утларын оештыруны тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу.

- Иске Иглай авылы территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу.

- Иске Иглай авылы халкының янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу.

Халык җыенында рәислек итүче: Р.Р. Рәхмәтуллин

Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Рәхмәтуллин